Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлегенең Нөнәгәр авылы торак пункытында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«29» октябрь 2025 ел № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Нөнәгәр авылы торак пункты халык җыены карар итте:

1. Үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән:1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, балачактан инвалидлар, 90 яшьтән өлкәнрәкләр, ятучы авыруларалар, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан башка; үзара салым суммасыныц 50 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары, ялгыз аналар, 18 яшькә кадәр балалары булган тол хатыннар, урта һәм югары уку йортларында көндезге формада белем алучы студентлардан башка 2026 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Нөнәгәр авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 650 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Нөнәгәр авылының торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Нөнәгәр авылындагы һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) урнаштыру, төзекләндерү һәм аларга янәшә урнашкан территорияне төзекләндерү;
- Нөнәгәр авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) ,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы,
Советы рәисе И.Н.Закиров